РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАМАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

423643 село Камаево, ул. Дифгата Сирая
д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 Камай авылы, Дифгать
Сирай урамы 29А йорты

Тел.(885549)3-55-33 ИНН 1627001164, КПП162701001 ОГРН 1021601118043

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 1 нче апреленнән № 26

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы «Камай авыл
җирлеге»нең җирдән файдалану һәм
төзелеш объектлары Кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү буенча карар
проекты турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Камай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2016 ел ның 26 нче августыннан № 29 номерлы карары белән раслаган “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш объектлары Кагыйдәләре”нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары.» 35 статьяның «Шәһәр төзелеше зонасы картасында билгеләнгән территориаль зоналар төрләре» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалыкалып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләрене ңминималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең максималь күләме - 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.».

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы Карары проектын карау буенча ачык тыңлауларны 2021 елның 3 маенда 11 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Камай авыл җирлеге, Камай авылы, Дифгать Сирая урамы, 29б, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең күп функцияле үзәге.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Камай авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" гы карары проекты белән танышу чорында әлеге проектның демонстратив материаллары экспозициясен оештырырга, кызыксынган затларның искәрмәләре һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Камай авыл җирлеге, Камай авылы, ул. Дифгать Сирая, 29б йорты ( Камай авыл җирлегенең күп функцияле үзәге);

5. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының tps://mendeleevsk.tatarstan.ru/ рәсми сайтында Камай авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

Камай авыл җирлеге Советы рәисе И.И.Әһлиева

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Камай авыл
җирлеге Советының 2021 елның
1 апреленнән 26 номерлы карарына
КУШЫМТА

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында " карары проекты буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча
комиссия составы

1. Рәисе: Әһлиева Инзилә Ильяс кызы -Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;

2. Рәис урынбасары: Кәлимуллин Рәмис Рафис улы - Камай авыл җирлеге Советы депутаты;

3. Секретарь: Зиннәтуллина Гүзәлия Мөнир кызы-Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;

4. Комиссия әгъзасы: Аннамородова Римма Борисовна-Камай авыл җирлеге Советы депутаты;

5. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы» инвестицион һәм инфраструктура үсеше идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.